**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

2020 елның «21» сентябреннән № 234

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында Үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты баш хисапчылары һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) вазыйфаи окладларын арттыру турында»**

Үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты баш хисапчылары һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты **карар бирә**:

1. 2020 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты баш хисапчылары һәм хисапчыларының Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты баш хисапчылары һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» 23.04.2009 ел, № 112 карары белән билгеләнгән вазыйфаи окладлары күләмнәрен 1,03 тапкырга арттырырга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары, шулай ук айлык һәм башка өстәмә түләүләр һәм арттырган

вакыттагы (индексация) түләүләр күләме тулы сумга кадәр арттыру ягына түгәрәкләндерелергә тиеш;

әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. «Яңа Чишмә муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты баш хисапчылары һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» 2019 елның 23 апрелендәге 112 номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карарының 3 пунктын гамәлгә яраксыз дип танырга.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, (халыкка җиткерергә) шулай ук Татарстан Республикасы_Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты**
**Җитәкчесе** **Р.Р. Фәсахов**